**Татарский язык с Г. Тукаем. Басни и детские рассказы**

Габдулла Тукай

МӘСӘЛЛӘР ҺӘМ БАЛАЛАР ӨЧЕН ХИКӘЯЛӘР (басни и детские рассказы; *мәсәл — басня; балалар — дети; бала — ребенок; өчен — для; хикәя — рассказ*)

Пособие подготовил **Рустэм Шайдуллин** (rustemsh@mail.ru)

*Метод чтения Ильи Франка*

***Аккош, чуртан һәм кыскыч***[1] (лебедь, щука и рак)

Бервакыт аккош, чуртан, кыскыч (однажды лебедь, щука, рак) — өчесе бер йөккә җигелеп (впрягшись втроем в одну упряжку: «втроем в одну упряжку впрягшись»; *өч — три; өчесе — трое; бер — один; йөк — воз, поклажа; җигелергә — впрягаться; җигәргә — запрягать*), аны алга алып бармакчы булдылар (собрались повезти ее вперед: «ее вперед повезти собрались»; *аны — ее, его; алга — вперед; алып — взяв; алырга — взять; бармакчы — в намерении пойти; барырга — идти, ехать; булырга — быть*).

Бервакыт аккош, чуртан, кыскыч — өчесе бер йөккә җигелеп, аны алга алып бармакчы булдылар.

Болар өчесе дә тиреләреннән чыгарлык булып (все трое из кожи вон лезут; *болар — эти; өчесе дә — все трое; тире — кожа; чыгарга — выйти;*

[1] Кыскыч — кысла (*кыскыч — клешня; кысла — рак*).

*чыгарлык булып — чуть ли не выходя*), көчәнеп тарталар (натужно тянут; *көчәнеп — тужась; тартырга — тянуть*), ләкин йөк һаман да кузгалмый (а воз все не движется; *ләкин — но; йөк — воз; һаман — до сих пор; кузгалмаска — не сдвигаться; кузгалырга — сдвигаться*). Бу йөк аларга, бәлки, авыр да булмас иде (возможно, этот воз и не был бы для них тяжел; *бу — этот; алар — они; бәлки — возможно; авыр — тяжелый*), ләкин аккош һавага тартыла (но лебедь тянется в воздух; *ләкин — но; һавага — в воздух; һава — воздух; тартылырга — тянуться*), кыскыч артка өстери (рак пятится назад; *арт — зад; артка — назад; өстерәргә — тащить*), чуртан суга таба тарта (щука в воду тянет; *су — вода; суга таба — в сторону воды*).

Болар өчесе дә тиреләреннән чыгарлык булып, көчәнеп тарталар, ләкин йөк һаман да кузгалмый. Бу йөк аларга, бәлки, авыр да булмас иде, ләкин аккош һавага тартыла, кыскыч артка өстери, чуртан суга таба тарта.

Боларның кайсы гаепле, кайсы хаклы (кто из них прав, кто виноват; *болар — эти; кайсы — который; гаеп — вина; хаклы — прав*) — анысында безнең эшемез юк (*не наше дело: «в том нашего дела нет»; анысы — то; без — мы; эш — дело; юк — нет*), ләкин йөк әле һаман да шул урында (а воз и ныне там; *әле — сейчас, ныне;шул — тот; урын — место*).

Боларның кайсы гаепле, кайсы хаклы — анысында безнең эшемез юк, ләкин йөк әле һаман да шул урында.

## *Алмас*[2]

Тимерчедәге иске тимер кисәкләре арасына (у кузнеца среди старых

---

[2] Алмас — алмаз.

железяк; *тимерче — кузнец; иске — старый; тимер — железо; кисәк — кусок; тимер кисәкләре — куски железа, железяки; ара — промежуток между*) бер алмас кылыч ташланып (один алмазный меч заброшен будучи; *кылыч — меч; ташланырга — бросаться, быть брошенным*), бу алмас шуннан базарга чыгарылып (был вытащен затем на базар; *бу — этот; шуннан — затем; чыгарылырга — быть вытащенным, выпущенным; чыгарырга — вытащить, выпустить*), базарда бер мужикка сатылган иде (и на базаре продан одному мужику; *сатылырга — быть проданным; сатарга — продать*).

Тимерчедәге иске тимер кисәкләре арасына бер алмас кылыч ташланып, бу алмас шуннан базарга чыгарылып, базарда бер мужикка сатылган иде.

Мужикның гыйлеме ни дәрәҗәдә икәне билгеле инде (известно уж, какая у мужика грамота; *гыйлем — грамота, образование; ни дәрәҗәдә — в какой степени; билгеле инде — известно уж*). Ул, алмасны саплап (он, насадив алмаз на черенок; *сапларга — насадить на черенок; вдеть /нитку/ в иголку*), аның илә урманга барып (пойдя с ним в лес: «с ним в лес пойдя»), чабатага җүкә[3] агачлары кисә башлады (на лапти липу начал резать = начал резать лыко; *чабата — лапоть; җүкә — липа; агач — дерево; кисәргә — резать; башларга — начинать*). Шулай ук самавыр куйганда чыралар яру (так же колоть лучину для самовара: «когда ставишь самовар»; *шулай ук — так же; куярга — ставить; чыра — лучина; ярырга — колоть*), мич якканда чыбыклар кисү (резать прутья для топки печи: «когда топишь печь»; *мич — печь;ягарга — топить, сжигать; чыбык — прут; кисү — резание; кисәргә — резать*), көз көннәрендә бакчада бәрәңге, шалкан казу (копать осенью на огороде картошку и репу; *көз — осень; көннәр — дни; көз көннәрендә — осенью; бакча — сад, огород; казу — выкапывание; казырга — копать*) — барчасы алмас хезмәте иде (все было работой алмаза; *барчасы — все это;*

[3] Җүкә — юкә (липа).

*хезмәт — служба; работа; иде — было*).

Мужикның гыйлеме ни дәрәҗәдә икәне билгеле инде. Ул, алмасны саплап, аның илә урманга барып, чабатага җүкә агачлары кисә башлады. Шулай ук самавыр куйганда чыралар яру, мич якканда чыбыклар кисү, көз көннәрендә бакчада бәрәңге, шалкан казу — барчасы алмас хезмәте иде.

Шул рәвешчә мужикка бер ел кадәре хезмәт иткәч (прослужив таким образом на мужика около года: «таким образом мужику до года прослужив»; *кадәре — вплоть до; хезмәт итәргә — служить*), алмас кителеп, теш-теш булып беткәч (алмаз, весь покрывшись зазубринами; *кителергә — отколоться; отломиться; теш-теш — зазубрина; теш — зуб; теш-теш булырга — быть весь в зазубринах; бетергә — закончиться; завершиться*), балалар алмасыбызга атланып, ат итеп уйный башладылар (дети стали играть, оседлав наш алмаз как лошадь: «лошадью сделав»; *бала — ребенок; атланырга — сесть верхом; ат — лошадь, конь; уйнарга — играть; башларга — начать*). Ахырда алмашың сабы да төшкәч (в конце концов, когда у алмаза отвалилась и рукоятка; *ахырда — в конце концов, в итоге; сап — рукоять, черенок; төшәргә — падать, спускаться*), аны сәке астына ташладылар (его бросили под лавку: «его под лавку бросили»; *сәке асты — под лавкой: «низ лавки»*).

Шул рәвешчә мужикка бер ел кадәре хезмәт иткәч, алмас кителеп, теш-теш булып беткәч, балалар алмасыбызга атланып, ат итеп уйный башладылар. Ахырда алмашың сабы да төшкәч, аны сәке астына ташладылар.

Шул ук сәке астында бер бәрән бар икән (под той же лавкой есть один барашек, оказывается; *шул ук — тот же, та же; сәке асты — под лавкой; бер бәрән — один барашек; бар — есть; икән — оказывается*). Бу бәрән

алмасның болай түбән дәрәҗәдә изелгәнен күргәч (этот барашек, увидев, до какой степени опустился алмаз: «на таком низком уровне униженным увидев»; *бу — этот; болай — так; түбән — низко; дәрәҗә — уровень, степень; изелгән — измятый, униженный; изелергә — быть измятым, униженным; күрергә — увидеть*):

— И бичара алмас (о, несчастный алмаз)! Синең бөтен дөньяны тоткан шөһрәтең кайда (где твоя всемирная слава: "весь мир державшая"; *синең — твоя; бөтен дөнья — весь мир; тоткан — державшая; тотарга — держать; шөһрәт — слава; кайда — где*)? Син чабатага җүкәләр хәзерләп (ты, заготовив лыко: «на лапти липу»; *син — ты; чабата — лапоть; хәзерләргә — заготавливать*), балчыклар казып (вскопав землю: «почвы вскопав»), иң ахырда балаларга уенчык булып йөрергә оялмыйсыңмы (не стыдишься быть детской игрушкой в итоге: «ходить в игрушках»; *иң ахырда — в самом итоге; балалар — дети; уенчык — игрушка; булырга — быть; оялмаска — не стыдиться; оялырга — стыдиться*)? — диде (сказал).

Шул ук сәке астында бер бәрән бар икән. Бу бәрән алмасның болай түбән дәрәҗәдә изелгәнен күргәч:

— И бичара алмас! Синең бөтен дөньяны тоткан шөһрәтең кайда? Син чабатага җүкәләр хәзерләп, балчыклар казып, иң ахырда балаларга уенчык булып йөрергә оялмыйсыңмы? — диде.

Алмас аңар каршы (алмаз ему в ответ: «алмаз ему напротив»): «Әйе, мин гаскәрләр кулында заманымда дошманнарга арысланнан гайрәтлерәк идем (да, в свое время в войсках я был отважней льва против врагов: «в войск руках»; *әйе — да; гаскәрләр — войска; кул — рука; заманымда — в мое время; дошманнар — враги; арыслан — лев; гайрәтле — отважный; иде — был; идем — я был*), әмма бу мужик кулына төшкәч (но, попав в руки этого мужика; *кулга төшәргә — попасть в руки*), дөрест (верно), начар хезмәтләрдә йөрим (в скверных службах хожу = занимаюсь скверным трудом; *начар —*

*скверный; йөрергә — ходить*). Ләкин бу тугърыда оят миңа булмый (но об этом стыда мне не будет = но стыдно будет не мне; *ләкин — но; бу тугърыда — об этом; оят — стыд; булмаска — не быть; булырга — быть*), бәлки минем ни эшкә яраганлыгымны белмәгән хуҗамгадыр» (возможно, не знающему на что я годен хозяину; *бәлки — возможно; мин — я; эш — дело; ни эшкә — какому делу; яраган — сгодившийся; белмәскә — не знать; белергә — знать; хуҗам — мой хозяин; хуҗа — хозяин*), — дип җавап бирде (ответил: «сказав ответ дал»).

Алмас аңар каршы: «Әйе, мин гаскәрләр кулында заманымда дошманнарга арысланнан гайрәтлерәк идем, әмма бу мужик кулына төшкәч, дөрест, начар хезмәтләрдә йөрим. Ләкин бу тугърыда оят миңа булмый, бәлки минем ни эшкә яраганлыгымны белмәгән хуҗамгадыр», — дип җавап бирде.

### ***Арыслан ауда*** **(лев на охоте)**

Эт, арыслан, бүре, төлкегә ничектер күрше торырга туры килеп (собаке, льву, волку и лисе пришлось как-то жить по соседству; *төлке — лиса; күрше — сосед; торырга — жить, стоять; ничектер — как-то; туры килергә — совпасть; прийтись, быть вынужденным*), болар дүртәве ни генә ауласалар да (что бы эти четверо ни добыли; *болар — эти; дүртәве — четверо; ни генә — что бы; ауларга — добыть на охоте*), дүрт өлешкә бүләргә сүз куештылар (договорились делить на четыре части; *өлеш — часть; бүләргә — делить; сүз куешырга — дать слово друг другу*).

Эт, арыслан, бүре, төлкегә ничектер күрше торырга туры килеп, болар дүртәве ни генә ауласалар да, дүрт өлешкә бүләргә сүз куештылар.

Көннәрдә бер көн бүре (однажды волк), бер болан тоткач (поймав оленя; *болан — олень; тотарга — поймать; держать*), иптәшләренә хәбәр бирде (дал знать товарищам; *хәбәр — весть, сообщение; бирергә — дать*).

Иптәшләр килделәр (товарищи пришли; *килергә — прийти*): табыш начар түгел (добыча неплоха; *начар — плохо, плохой; түгел — не*).

Көннәрдә бер көн бүре, бер болан тоткач, иптәшләренә хәбәр бирде.

Иптәшләр килделәр: табыш начар түгел.

Арыслан бик мөтәкәббиранә[4] бер сурәттә генә (лев с очень важным видом) болан янына килеп утырып (подойдя к оленю и усевшись; *янына — к; килергә — подойти, приходить; утырырга — сесть*), боланны дәрхаль[5] дүрт кисәккә бүлеп ташлап (разделав его тотчас же на четыре куска; *кисәк — кусок; бүлеп ташларга — разделать*), сөйләргә тотынды (принялся говорить; *сөйләргә — говорить; тотынырга — приниматься, браться*): «Менә, дустлар (вот, друзья), без дүртәү инде (раз уж нас четверо; *без — мы, нас; инде — уж*); әйдәгез, бүлә башлыйк (давайте начнем делить; *бүләргә — делить*); менә тыңлагыз (вот слушайте; *тыңларга — слушать*): бу беренче кисәк миңа (этот первый кусок мне) — вәгъдәбез буенча (по нашему уговору; *вәгъдә — уговор*). Икенчесе миңа (второй мне) — минем арыслан булганым өчен (за то, что я лев). Өченче кисәге минеке (третий кусок мой) — аның өчен мин барыгыздан да көчлерәк (ибо я вас всех сильнее; *барыгыз — все вы; көчле — сильный*). Әмма дүртенче кисәккә кайсыгыз гына кул сузса да (но кто бы из вас ни потянулся за четвертым куском; *әмма — но; дүртенче — четвертый; кисәк — кусок; кайсыгыз гына — который бы из вас; кул — рука; сузарга — тянуть*), урыныннан тере тормас (тот не поднимется живым со своего места; *урын — место; тере — живой; тормаска — не вставать;*

---

[4] Мөтәкәббиранә — олы сыман, эреләнеп (важничая).

[5] Дәрхаль — шунда ук (там же, тогда же, тотчас же).

*торырга — встать*), беленез аны (знайте это)!..»

Арыслан бик мөтәкәббиранә бер сурәттә генә болан янына килеп утырып, боланны дәрхаль дүрт кисәккә бүлеп ташлап, сөйләргә тотынды: «Менә, дустлар, без дүртәү инде; әйдәңез, бүлә башлыйк; менә тыңлаңыз: бу беренче кисәк миңа — вәгъдәбез буенча. Икенчесе миңа — минем арыслан булганым өчен. Өченче кисәге минеке — аның өчен мин барыгыздан да көчлерәк. Әмма дүртенче кисәккә кайсыгыз гына кул сузса да, урыныннан тере тормас, беленез аны!..»

***Арыслан илә тычкан* (лев и мышь)**

Тычкан, арыслан янына килеп (мышь, придя ко льву; *килергә — прийти, подойти*), тәгъзим берлә генә[6] (с почтением), шул якын-тирәдә бер агач төбенә ояларга рөхсәт сорады вә диде (попросила разрешения вырыть нору неподалеку под деревом и сказала; *шул — тот, та; якын-тирә — окрестность; агач төбе — под деревом: «основание дерева»; оя — нора, гнездо; рөхсәт — разрешение; сорарга — спросить; вә — и*): «И падишаһ (о, повелитель)! Син гәрчә урманда иң көчле вә гайрәтле бер зат булсаң да (даже если ты в лесу самый сильный и храбрый; *син — ты; гәрчә — хоть; урман — лес; иң — самый; көчле — сильный; гайрәтле — храбрый; зат — персона, особа; булырга — быть; да — даже*), гәрчә синең бер нәгъррән[7] бөтен җанварларны тетрәтергә җитсә дә (даже если от одного твоего голоса все звери в лесу дрожат: «голоса достаточно заставить дрожать»; *бөтен — все; җанварлар — звери; тетрәтергә — заставить дрожать, трепетать; тетрәргә — дрожать; җитәргә — хватать, быть достаточным*),

---

[6] Тәгъзим берлә генә — олылап кына (с почтением).
[7] Нәгърә — гайрәтле, көчле тавыш (сильный голос).

киләчәкне белеп булмый бит (невозможно предугадать будущее; *киләчәк — будущее; белергә — знать; булмаска — не быть; бит — ведь*). Кем белә (кто знает; *кем — кто*)? Бәлки, мин шушы кадәр зәгыйфь вә көчсез бер мәхлук булсам да (возможно, несмотря на то что я настолько ущербное и слабое создание; *бәлки — возможно; шушы кадәр — настолько; зәгыйфь — ущербный, уродливый; көчсез — бессильный, слабый; көчле — сильный; мәхлук — существо, тварь*), бервакыт сезгә бер файда тиерермен (однажды окажусь вам полезен; *бервакыт — однажды, когда-нибудь; файда тиерергә — быть полезным: «пользой коснуться»*)».

Тычкан, арыслан янына килеп, тәгъзим берлә генә, шул якын-тирәдә бер агач төбенә ояларга рөхсәт сорады вә диде: «И падишаһ! Син гәрчә урманда иң көчле вә гайрәтле бер зат булсаң да, гәрчә синең бер нәгърәң бөтен җанварларны тетрәтергә җитсә дә, киләчәкне белеп булмый бит. Кем белә? Бәлки, мин шушы кадәр зәгыйфь вә көчсез бер мәхлук булсам да, бервакыт сезгә бер файда тиерермен».

Арыслан, тычканның бу сүзләренә гаять тә ачуланып (лев, разгневавшись на эти слова мыши; *сүзләр — слова; гаять — крайне; ачуланырга — рассердиться*): «Синме (ты что ли)?! И кызганыч җанвар (жалкое животное)! Кит, югал хәзер күземнән (сгинь, исчезни с глаз моих долой; *китәргә — уйти; югалырга — потеряться, исчезнуть; хәзер — сейчас; күз — глаз*)! Тере вакытта тизрәк башыңны алып кач (убирайся подобру-поздорову; тере вакытта: «в то время, пока живой»; *тере — живой; вакыт — время; тизрәк — быстрей; тиз — быстро; башыңны алып кач — «спасай свою голову»; башың — голова твоя; баш — голова; алырга — брать; качарга — прятаться, спасаться*). Югыйсә мин сине дөньяга килмәгән шикелле итәрмен (иначе сотру тебя с лица земли: «сделаю, словно ты не приходил на этот свет»; *югыйсә — иначе: дөнья — мир, свет; килмәскә — не приходить; шикелле — словно; итәргә — делать*). Миңа, арысланга,

файдам тияр дигән була бит (говорит, мол, окажется полезен мне, льву; *миңа — мне; дигән була — говорит мол; диярга — сказать; бит — ведь*)! Ах, әдәпсез нәрсә (неучтивое создание; *нәрсә — создание; вещь*)!» — дип, бик каты гайрәтләнде (разъярился; *бик — очень; каты — твердый, крепкий; гайрәтләнергә — возмущаться*).

Арыслан, тычканның бу сүзләренә гаять тә ачуланып: «Синме?! И кызганыч җанвар! Кит, югал хәзер күземнән! Тере вакытта тизрәк башыңны алып кач. Югыйсә мин сине дөньяга килмәгән шикелле итәрмен. Миңа, арысланга, файдам тияр дигән була бит! Ах, әдәпсез нәрсә!» — дип, бик каты гайрәтләнде.

Тычкан мискин бар хәле белән (бедняжка мышка изо всех сил; *мискин — бедняжка*), җан коткарыр өчен (чтобы спастись; *җан — душа; коткарырга — спасти; өчен — чтобы*), качып, күздән дә югалды (спрятавшись, исчезла с глаз; *качарга — спрятаться; күз — глаз; югалырга — исчезнуть*).

Ләкин арысланның бу тәкәбберлеге буш кына калмады (но льву эта его спесь не прошла даром; *ләкин — но; тәкәбберлек — спесь; буш калырга — пройти даром*).

Тычкан мискин бар хәле белән, җан коткарыр өчен, качып, күздән дә югалды.

Ләкин арысланның бу тәкәбберлеге буш кына калмады.

Бервакыт ул, үзенә азык эзләргә чыкканда (однажды он, выйдя на поиски добычи /для себя/; *ул — он; үзенә — для себя, себе; азык — еда, эзләргә — искать; чыгарга — выйти*), яңлыш аучының үләннәр арасына корган авына эләкте (нечаянно попал в охотничью западню, устроенную в зарослях; *яңлыш — нечаянно; аучы — охотник; үлән — трава; ара — между; корырга — устроить, смастерить; ау — западня; охота; эләгергә —*

*попасться*). Монда инде нәгърәләр, үкерүләр файда бирми (здесь уже ни крики, ни рыдания бесполезны; *монда — здесь; инде — уже; нәгърә — крик; үкерү — рыдание; файда — польза; бирмәскә — не дать*).

Бервакыт ул, үзенә азык эзләргә чыкканда, яңлыш аучының үләннәр арасына корган авына эләкте. Монда инде нәгърәләр, үкерүләр файда бирми.

Мискин арыслан никадәр тартылса да, җолкынса да (сколько бы бедный лев ни тянулся, ни дергался; *мискин — бедный; никадәр — насколько; тартылырга — тянуться; җолкынырга — дергаться, вырываться*), аучының табышы гына булып калды (оказался всего лишь добычей охотника; *аучы — охотник; табыш — добыча; булып калырга — оказаться*): аны шәһәргә алып кайтып, кешеләргә күрсәтер өчен, тимер читлеккә ябып куйдылар (его привезли в город, и, чтобы показывать людям, заперли в железную клетку; *шәһәр — город; алып кайтырга — привезти: «взяв вернуться»; кешеләр — люди; күрсәтергә — показывать; тимер — железная; читлек — клетка; ябып куярга — запереть*).

Мискин арыслан никадәр тартылса да, җолкынса да, аучының табышы гына булып калды: аны шәһәргә алып кайтып, кешеләргә күрсәтер өчен, тимер читлеккә ябып куйдылар.

Арыслан читлек эчендә теге тычканны исенә төшерде (в клетке лев вспомнил ту мышку; *читлек эчендә — внутри клетки; теге — та; искә төшерергә — вспомнить*). Әгәр тычканга шәфкать иткән булса (если бы проявил милосердие к мышке: «сделал милосердие»; *әгәр — если; шәфкать — милосердие; булса — был бы*), ул, ауның җепләрен кимереп өзеп (она перегрызла бы охотничьи путы; *җепләр — веревки, путы; кимерергә — грызть; өзәргә — рвать*), арысланны бәладән коткара алачак иде (и смогла бы спасти льва из беды; *бәла — беда; коткара алырга — смочь спасти*).

Арыслан читлек эчендә теге тычканны исенә төшерде. Әгәр тычканга шәфкать иткән булса, ул, ауның җепләрен кимереп өзеп, арысланны бәладән коткара алачак иде.

*

Коега төкермә (не плюй в колодец; *кое — колодец; төкермәскә — не плевать*), бервакыт су эчәргә кирәк булыр, диләр (пригодится однажды воды напиться, говорят; *су — вода; эчәргә — пить; кирәк — нужно*).

Коега төкермә, бервакыт су эчәргә кирәк булыр, диләр.

---

*Полностью книгу можно купить на сайте www.franklang.ru в соответствующем языковом разделе (татарский язык), в подразделе «Тексты на татарском языке, адаптированные по методу чтения Ильи Франка»*